

# БЕЗ - БЕРГӘ!

## (өлкәннәр клубы)



"Без – бергә!" өлкәннәр клубының девизы:

***Үткән еллар***

***бик зур байлык бит ул,***

***Гыйлем һәм тәҗрибә тулы***

***сандык бит ул!***



Клубның оешкан елы: 2013 ел.

Клубның оешкан урыны:

Балтач үзәк китапханәсе.

# “Без – бергә!” өлкәннәр клубы

# УСТАВЫ

I. **Гомуми мәгълүматлар:**

1. Клуб 2013 елның 1 февралендә Балтач үзәк китапханәсе каршында оешты
2. “Без – бергә!” өлкәннәр клубы җәмгыяви оешма, китапханә һәм өлкән китап укучыларның ирекле берләшмәсе булып тора.
3. Клуб әгъзасы булып 55 яшьтән өлкән, клуб Уставын үтәгән китап укучылар тора ала.
4. Клубка кабул ителү өчен телдән гариза да җитә.
5. Үз эшчәнлегендә Клуб әлеге Уставка таяна.

II. **Клубнын җитәкчесе:** Нәбиева Илсөяр Хуҗамөхәммәт кызы – зурлар китапханәсенең абонемент бүлеге китапханәчесе.

III. **Клубның максаты:** китапханәдә өлкәннәр өчен оештырылган һәр масса-чарада – календарь бәйрәмнәр, танылган шәхесләрнең юбилей даталары уңаеннан үткәрелүче тематик кичәләрдә, театраль тамашаларда, уеннарда һ.б. чараларда катнашу.

IV. **Клубының төп бурычлары:**

1. Клуб әгъзаларының буш вакытларын файдалы һәм күңелле итеп оештыру.
2. Аларны үзара аралаштыру.
3. Талантларны, сәләтләрне барлау.
4. Матур әдәбият белән таныштыру.

V. **Клуб әгъзаларының хокуклары.**

1. Клубның һәр әгъзасы клуб эшендә үз теләге белән катнаша.

2. Клубның эшен планлаштыруда һәм тормышка ашыруда һәр клуб әгъзасының хокуклары бертигез.
3. Клуб әгъзалары масса-чаралар үткәрү буенча тәкъдимнәр, сценарийларга төзәтмәләр кертә һәм чараның үткәрелү вакытын билгели алалар.
4. Клуб әгъзалары үткәреләчәк кичәдә роль башкаруга үзләренең кандидатураларын тәкъдим итәргә хокуклы.

**VI. Клуб әгъзаларының бурычлары.**

1. Клубның барлык әгъзалары да китапханә тәртибен үтәргә;
2. Китапханәгә йөрергә;
3. "Без – бергә!" өлкәннәр клубы Уставын үтәргә;
4. Утырыш, кичәләрдә мөмкин кадәр даими катнашырга;
5. Клуб тормышында актив катнашырга тиешләр.

**VII. Кадрлар составы.**

1. Клубның җитәкчесе клуб эшчәнлеге белән идарә итә, катнашучыларга репетицияләрнең кайчан һәм кайда булуын хәбәр итә.
2. Техник бизәлеш буенча җаваплы кеше белдерү әзерли, презентация ясый.
3. Музыка өлешенә җаваплы кеше музыкаль бизәлешне тәэмин итә.

**VIII. Кичәне әзерләү.**

1. Репетицияләрне клуб җитәкчесе күзәтеп бара, үз фикерен әйтә ала.
2. Масса-чаралар үзәк китапханәнең уку залында уза.

**IX. Әлеге Устав яңадан редакцияләнә һәм кирәк очракта аңа өстәмәләр кертелә ала.**

Гомер дисбесенә бер-бер артлы
Еллар мәрҗән кебек тезелсә дә,
Йөрәк санамасын ул елларны,
Күңелнең дә картаймасын ла кыллары,
Чәчләребез көмеш белән бизәлсә дә...
*Илсөяр Нәбиева*

Яшьлекне гөрләвекле, кояшлы язлар белән чагыштырсалар, олыгайган чорны нигәдер көзләргә тиңлиләр. Бу чагыштыруда хаклык та бар. Көз галиҗәнап безне янып торган төсләр дингезенә алып керен китә дә, яз-җәй тырышып эшләгәннең әҗерен күрсәтеп, бакча-кырларыбызда мул уңыш белән сөендерә. Адәм баласы да бит олыгайган мәлдә, табигатьнең көзендәге кебек, үткәненә, гомер язларына бер әйләнеп карый. Еракларда калган елларын сагынып бер уфтанса, инде үсеп җиткән балаларына, янәшәдә шау-гөр килеп уйнаган оныкларына карап, янә бер шатлана.

Әйе, “гомер көзе” диеп сөйләшкәндә һич кенә дә яңгырлы, җилле көзне уйлыйсы килми.

Язларга тиңләгән яшьлек кайчан тәмамлана да, көзләргә тиңләгән картлык кайчан башлана? Аларның чикләре кайда соң? Аны белү кирәкме, әллә шул чикне белмәгәннәр бәхетлеме? Бу сорауларга җавапны һәркем үзенчә бирер. Әмма “Картаюны сизмәгәннәр бәхетле”, - дип юкка гына әйтмәгәннәрдер.

Россия Федерациясе кануннары буенча, бүгенге көндә, кайбер искәрмәләрне исәпкә алмаганда, хатын-кызлар – 55, ир-атлар 60 яшьтән лаеклы ялга чыга алалар. Менә шушы яшь чикләреннән алып, өлкәннәр дигән буын билгеләнә. Бу, бер карасаң, четерекле мәсьәлә дә. Кемнәрнеңдер үзләрен һич кенә дә өлкәннәр сафына кертәселәре килмәс...

Лаеклы ял яшенә җитүгә кайберәүләр хезмәт юлын төгәлли, кайберәүләр яраткан эшләрен дәвам итәләр. Галимнәр фикеренчә, лаеклы ялга чыгып, җәмгыять белән мөгамәләне кинәт өзгән, өйдә утыра башлаганнар бу хәлне психологик яктан бик авыр кичерә. Юкка гына, мәсәлән, Америка Кушма Штатларында әлеге категория халкы өчен махсус түгәрәкләр, клублар һәм башка шуның ише берләшмәләр күпләп оештырылмый. Алар биредә үзләренең күңелләренә якын шөгыль табалар, бер-берсе белән аралашу өчен көндәлек күрешеп торалар. Лаеклы ялга чыгучылар үзләрен хәтта икенче эшкә күчкән кебек кенә хис итәләр.

Безнең үзәк китапханәбездә оештырылган “Без – бергә!” өлкәннәр клубы да нәкъ шушы максатларны күздә тотып төзелде. Без – китапханәчеләр, үзәк китапханәгә йөрүче өлкән буын китап укучыларыбызга сокланып, гаҗәпләнеп карыйбыз да, алар турында җәйдә калганнар” дип әйтә алабыз. Әйе, әйе, нәкъ менә җәйдә – бар табигать күкрәп, үсеп торган, җылы-якты җәйдә. Безнең клубка йөргән китап укучыларыбыз еллар үткәннәргә уфтанмыйча, күңеле, рухы белән яшь калганнар рәтеннән.

“Без – бергә!” өлкәннәр клубына йөрүчеләрнең барысын да бер матур сыйфат – китапка мәхәббәт, кешеләрне ярату берләштерә. Клуб үткәргән чараларда өлкәннәребез күңелләренә кеше белән аралашу дигән мөһим шифа, китап укып, җаннарына рухи ризык алалар. Китапханәдә оештырылган чараларда да өлкәннәребез бик теләп катнашалар, алар безнең өчен – кадерле кунак.

“Без – бергә!” өлкәннәр клубы әгъзалары арасында кемнәр генә юк: шагыйрәләр, язучылар (китап авторлары), гармунчылар, журналистлар, җырчылар, артистлар, “оста куллар” ияләре... Шушы матур, гаҗәеп бай һәм кыңкырлы даирәдә үткәрелгән кичәләребез гөрләп тора, бик күңелле була.

Китапханәбездә бер матур гадәт яшәп килә. Өлкәннәр көнендә без иң өлкән китап укучыбызны билгеләп үтәбез.

Әнә шундый яшәү дәрте, иҗат дәрте белән янучы өлкәннәребез булу белән без – китапханәчеләр бик бәхетле. Алар биргән киңәшләр эшебезне җиңеләйтә, өлкәннәребездән үзебезнең тарафка һәрдаим җылы хуплау сүзләрен ишетү, хезмәтебезне бәяләү безгә эш дәрте өсти, канат куя.

... Көзләр ел саен килә. Гомернең язы да, көзе дә ашкынулы бер мизгел ул. Язларның гүзәллеген, көзләрнең бәрәкәтен, кадерен белеп калырга насыйп итсен! Мәгълүм җырдагыча, “Мои года – моё богатство!” – “Минем елларым – минем байлыгым!” дип яшәргә язсын!



Үткәннәр аша бүгенгә




Инде күпме юллар үтелгән
Гомер язы шау чәчәктә
Тарихта калган еллар
Гаилә белән укыйбыз
ЗАМАН һәм КИТАПХАНӘ
ВЫХОД



